# Дидактик уен
# «Яшелчә, җиләк- җимеш бакчасында»
# (5-6  яшьлек балалар өчен)



**Тәрбияче: Яруллина Л. А**

**2016 ел**

# Максат:

- Балаларның яшелчәләр, җиләк-җимешләр турында белемнәрен системалаштыру.



# Бурычлар:

- Балалар сөйләмендә «Яшелчә», «Җиләк-җимеш» гомумиләштерүче сүзләрен ныгыту, җиләк-җимеш һәм яшелчәләрнең исемнәрен, кайда үсүләрен белүләрен камилләштерү.
- Уйлау-фикерләү сәләтен үстерү.
- Җиләк-җимеш һәм яшелчәләрнең сәламәтлеккә файдасын төшендерү.
- Вак кул мускулатурасын ныгыту.



# Жиhазлау:

- Агач, түтәл макетлары.
- Яшелчә, җиләк-җимеш рәсемнәре (УМК комплектыннан алынды).
- Ел фасыллары турында табышмаклар.



# Уен барышы:

**1 вариант.Тәрбияче балалар алдына түтәл һәм агач макетлары, ә тартмага яшелчә, җиләк-җимеш рәсемнәре куя, беренче баладан агачта нәрсә үсүен сорый, җиләк-җимешләрне аерып алып аларны агачка беркетергә куша. Икенче баладан түтәлдә нәрсә үсүен сорый, яшелчәләрне аерып алып түтәлгә утыртырга куша.**

**2 вариант.Тәрбияче агач макетына яшелчә һәм җиләк-җимеш куя. Бала хатаны табарга бары тик агачта үсүче җиләк-җимешне генә калдырырга тиеш, ә калганнары кая үсәргә тиешлеген баладан әйттерү, түтәл алу һәм хатаны төзәтү.**



**3 вариант.** Тәрбияче балалар алдына җиләк- җимешләр яшелчәләр куя, балалардан алларында нәрсәләр күрүләрен сорый,ике төркемгә бүлүләрен үтенә , бала ни өчен шулай, ә башкача түгел икәнен исбатларга тиеш.

**4 вариант.** Бу уенда 4-5 бала уйный. Балалар яшелчәләрнең һәм җиләк-җимешләрнең кайда үсүе һәм аларның сыйфатлары турында сөйлиләр. Мәсәлән: бу кыяр- яшел төстә, озынча, тәмле, ул түтәлдә үсә, кыяр файдалы, аннан салат ясыйлар, кыяр күп ашасагыз, тиз үсәрез.



## Уенның нәтиҗәлелеге:

- Балаларның фикерләү, уйлау сәләте үстерелә;
- « Яшелчә, җиләк-җимеш турында белемнәре баетыла;
- Сүз байлыгы арта, сөйләм теле үсә;
- Вак кул мускулатурасы ныгый.

